**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2023 елның 28 феврале 30-РС номер

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы уставының 47, 48 статьялары, «Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 11 сентябрендәге 52-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары белән (2023 елның 31 гыйнварындагы 21-РС номерлы үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә һәм аны, 2023 елның 29 мартында Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, уздырырга (үткәрү вакыты - 09.00 сәг., үткәрү урыны - Лаеш муниципаль районы Советының кече залы).

Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документлар кабул итү 2023 елның 1 мартыннан 20 мартына кадәр түбәндәге адрес буенча башкарыла: 422610, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Первомайская урамы, 39 йорт, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составын (алга таба - конкурс комиссиясе) Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатуралар карауга конкурс комиссияләре әгъзалары исемлегенә үзгәреш

кертү турында» 2022 елның 19 февралендәге ПУ-142 номерлы Указы белән, кушымта нигезендә, расларга.

3. Конкурс комиссиясенә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрергә, конкурс нәтиҗәләрен һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына кандидатлар турында мәгълүмат бирергә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында «Кама ягы»(«Камская Новь») район газетасында хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Башлыгы урынбасары- Совет рәисе урынбасары Т. П. Борһановага йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**

районы Советының 2023 елның ____ _-номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составы**

| № | Ф.И.Аи. | Эш урыны, вазыйфасы | Кем тарафыннан билгеләнгән | Комиссия составындагы статус |
|---|---|---|---|---|
| *1.* | Борһанова Татьяна Петровна | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы урынбасары | Лаеш муниципаль районы Советы тарафыннан | Комиссия рәисе |
| *2.* | Карсалов Андрей Геннадьевич | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | Лаеш муниципаль районы Советы тарафыннан | Комиссия рәисе урынбасары |
| *3.* | Агмалов Расиль Равил улы | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы аппаратының оештыру бүлеге башлыгы | Лаеш муниципаль районы Советы тарафыннан | Комиссия секретаре |
| *4.* | Белов Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты җитәкчесе | Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан | Комиссия әгъзасы |
| *5.* | Мөхәммәтшин Наил Рәшит улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсенең баш киңәшчесе | Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан | Комиссия әгъзасы |
| *6.* | Самаренкин Дмитрий Анатольевич | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Казан май комбинаты» акционер җәмгыятенең директорлар советы рәисе (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан | Комиссия әгъзасы |